**СОВЕТ МЕМДЕЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422728, Республика Татарстан, Высокогорский район, с.Мемдель, ул. Кооперативная, 30

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МӘМДӘЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422728, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Мәмдәл авылы, Кооператив урамы, 30

тел./факс 8(84365) 60-2-37, e-mail: Memdel.Vsg@tatar.ru

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**20 октябрь 2020 г.** **№ 7**

## Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мәмдәл авыл җирлегендә территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру Тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү турында 2020 елның 20 июлендәге 236-ФЗ номерлы Федераль закон, «Биектау муниципаль районының Мәмдәл авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Мәмдәл авыл җирлеге Советы,

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Биектау муниципаль районы Мәмдәл авыл җирлеге Советының 2014 елның 25 декабрендәге 193 нчы номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Мәмдәл авыл җирлегендә территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру Тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 13 статьяны түбәндәге эчтәлекле 1.1. өлеш белән тулыландырырга:

«1.1. Территориаль иҗтимагый үзидарә органнары проект инициаторлары буларак инициатив проектны тәкъдим итәргә мөмкин.»;

2) 14 статьяның 4 өлешен түбәндәге эчтәлекле 7 пункт белән тулыландырырга:

«инициатив проект буенча фикер алышу һәм аны хуплау мәсьәләсе буенча карар кабул итү.».

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ авыл җирлекләре бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар 2021 елның 1 январеннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мәмдәл авыл җирлеге башлыгы Ф.Г.Сафиуллинга йөкләргә.

Совет рәисе,
Мәмдәл авыл җирлеге Башлыгы Ф.Г.Сафиуллин